# ТАТАР ТЕЛЕ – МИЛЛӘТ ТЕЛЕ!!

Татар теленең башка телләр арасында юкка чыгып баруында иң башта гаепне үзебездән эзләргә кирәк. Чөнки ана телен, милләтне саклау чаралары бала тумас борын башланырга тиеш. Әйтик, шул яшь татар гаиләсендә беренче мәхәббәт җимешләре дөньяга килгәндә яшь әни буласы, әти буласы кешеләр татарча сөйләшмәсә, гаиләдә рус теле өстенлек итсә, әлбәттә, бу гаиләдә бала тугач та үзгәреш булмый. Чөнки алар татарча яшәмиләр, аларның балалары да, үзләре кебек, ана теленнән мәхрүм булган мескен-манкорт булып үсәчәк. Баланы мәктәпкә барганчы туган, ана телендә тәрбияләргә безгә кем комачаулый? Татар гаиләсендә туып, үз телендә сөйләмәгән балалар өчен тик ата-аналары үзләре гаепле. Бу кешеләр милләт алдында гаеплеләр, туган телебезнең югалып баруына сәбәпчеләр. Үз илендә, үз җирендә, үз милләте арасында яшәсәләр дә.

Ә менә чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез тел мәсьәләсенә бик җитди һәм җаваплы карыйлар, мактауга һәм алардан үрнәк алуга лаеклылар. Алар үз телләреннән оялмыйча, татар булулары белән горурланып, төрле илләрдә, яшәгән җирләрендә башка милләт халкына үрнәк булып, татар халкының бай тарихы белән, сәнгате, гореф-гадәтләре белән таныштырып, ана телен онытмыйча, татар телендә сөйләшеп, милләт сулышы белән “Без татарлар” диеп горурланып яшиләр.

## МӘКТӘП

Элекке Верный, хәзерге Алматы шәһәрендә 1нче гильдиялы татар сәүдәгәре Исхак Габдулгалиев салдырган кафедраль мәчет бинасында 1920нче елларда “Гаспринский” исемендә 9 еллык урта белем бирә торган татар мәктәбе эшли башлый. Директоры Бикбулатов Мөхәррәм була.

1937нче елда Бикбулатов Мөхәррәмне, Хисаметдинов Билялны, Бикбаев Сафаны һәм башка мөгаллимнәрне “халык дошманы” диеп кулга алалар һәм үлем җазасына хөкем итәләр. Мәктәп ябыла.

## ТЕАТР

Верный шәһәрендә, “Дворянское собрание” бинасында 1905нче елларда профессиональ артист Хан Исмагилов бер төркем үзешчән артистлар белән Галиәсгар Камалның “Беренче театр” исемле комедиясен сәхнәгә куя. Театрның меценатлары – татар байлары: Исхак Габделгалиев, Зәйнетдин Таҗетдинов була.

1934нче елда аларны да “халык дошманы” дип кулга алалар. Театр ябыла. Хан Исмагилов качып котыла, соңыннан Казанга кайтып, колхоз-совхоз театрларында эшли башлый.

## ТАТАР ХАТЫНЫ – МИЛЛӘТ АНАСЫ!!

Тел бит – милләт. Тел югалса, милләт югала.
Үз телендә сөйләмәгән милләт –
Милләт булып ничек таныла?

Без беркайчан да онытырга тиеш түгел: “Татар хатыны – милләт анасы” дигән сүзләрне.

Анасы нинди телдә сөйләсә, баласы да шул телдә сөйли. Шул телдә аның теле ачыла.

Тел югала, милләт бетә, диеп кычкырып, сүз куертып йөрүчеләргә минем болай дип әйтәсем килә: “Гасырлар аша, төрле сынаулардан үтеп, тарих катламнарында җуелмаслык эзләр калдырган, үзенең татар милләте, дәүләте булган һичкайчан югалмаячак!”

Милләт турысында уйлый башласам, киләчәккә өмет биреп, күңелдә шушындый шигъри юллар туа:

Татар хатыны – милләт анасы!!.
Милләтем, дип тибә йөрәге.
Яшәешнең ямьле балкышы!!
Татар дөньясының терәге!

*Татар Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре,*
*Татарстанның язучылар берлеге әгъзасы*
*Равил Гозәиров*